ГЛАВА ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
проспект Нефтяников,дом 30,
город Елабуга, 423603

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ
Нефтьчеләр проспекты,3 0нчы йорт,
Алабуга шәһәре, 423603

Тел.: (85557) 3-11-76, факс (85557) 3-82- 52, сайт: городелабуга.рф

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«03» сентябрь 2025 ел Алабуга шәһәре № 18

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2019 елның 29 июлендәге 631 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. 1 нче кушымта нигезендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия составын;

1.2. 2 нче кушымта нигезендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турындагы Нигезләмәне.

3. Алабуга муниципаль районы Башлыгының «Алабуга муниципаль районында ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү

турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы 4 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Район Башлыгы Р.М. Нуриев

Татарстан Республикасы Алабуга
муниципаль районы Башлыгының
2025 елның 3 сентябрендәге
18 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе | Алабуга муниципаль районы Башлыгы |
| Комиссия рәисе урынбасары | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары |
| Комиссия рәисе урынбасары | Җәмәгать тәртибен саклау буенча полиция башлыгы у рынбасары (килешү буенча) |
| Комиссия рәисе урынбасары | Россиянең Татарстан Республикасы буенча җәза үтәү федераль хезмәте җинаять башкарма инспекциясе идарәсе федераль казна учреждениесенең Алабуга муниципальара филиалы башлыгы урынбасары, (килешү буенча) |
| Комиссия секретаре | Россиянең Татарстан Республикасы буенча җәза үтәү федераль хезмәте җинаять башкарма инспекциясе идарәсе федераль казна учреждениесенең Алабуга муниципальара филиалы пробация төркеме өлкән инспекторы, (килешү буенча) |
| Комиссия әгъзалары: | |
| | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |

| | |
|---|---|
| | Алабуга районындагы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| | Россия Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлегенең балигъ булмаганнар эшләре бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| | Татарстан Республикасы буенча Россия Федераль миграция хезмәте идарәсенең Алабуга районындагы бүлек башлыгы (килешү буенча) |
| | «Алабуга шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының медицина хезмәте күрсәтү буенча урынбасары (килешү буенча) |
| | «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе психиатр-наркологы (килешү буенча) |
| | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының торакны исәпкә алу һәм бүлү бүлеге башлыгы |
| | «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы |
| | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторы мөдире |
| | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәтен үстерү секторы мөдире |
| | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |

Татарстан Республикасы Алабуга
муниципаль районы Башлыгының
2025 елның 3 сентябрендәге
18 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Россия Федерациясендә пробация турында»
Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссиясе турында
Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча муниципаль ведомствоара комиссия (алга таба - муниципаль комиссия) - Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы каршындагы даими эшләүче координация органы, ул Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, башкарма хакимиятнең федераль органнарының территориаль органнары, гражданлык җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм әлеге муниципаль берәмлектә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы башка оешмалар белән пробация кулланыла торган затларны ресоциализацияләү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә.

1.2. Муниципаль комиссия үз эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2019 елның 29 июлендәге 631 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль хокукый актлары, шулай ук «Россия Федерациясдә пробаия турында» Федераль закон нигезләмәләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм оешмалар белән пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү мәсьәләләре буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеге Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә

ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланып гамәлгә ашыра.

1.4. Муниципаль комиссия эшчәнлеге ресоциальләштерүдә, социаль адаптациядә һәм социаль реабилитациядә ярдәм күрсәтү күздә тотылган затларның ихтыяр белдерүе принципларына нигезләнә.

## 2. Муниципаль комиссиянең төп бурычлары

Муниципаль комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

2.1.Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында хөкем ителгәннәргә карата кулланыла торган чаралар комплексын, җинаять-хокукый характердагы башка чаралар билгеләнгән затларга һәм авыр тормыш хәлендә калган мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәүче оешмалардан азат ителгән затларга карата кулланыла торган чаралар комплексын гамәлгә ашыру, шул исәптән:

һөнәри юнәлеш һәм хезмәт адаптациясе;

торак һәм көнкүреш төзелеше;

медицина ярдәме күрсәтү;

белем алу;

социаль хезмәт күрсәтү хокукын гамәлгә ашыру;

психологик ярдәм;

юридик ярдәм;

югалган социаль элемтәләрне һәм функцияләрне торгызуга ярдәм итү;

пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерүнең, социаль адаптацияләүнең һәм социаль реабилитацияләүнең башка рәвешләре.

2.2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, граждан җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән пробация кулланыла торган затларны ресоциализацияләү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү мәсьәләләре буенча эшчәнлеген координацияләүне һәм аларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү.

2.3. Пробация кулланыла торган затларның бердәм реестрын алып бару.

2.4. Кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау.

2.5. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү буенча үткәрелә торган эш турында җәмәгатьчелеккә хәбәр итү.

## 3. Муниципаль комиссия вәкаләтләре

Муниципаль комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

3.1. Индивидуаль тәртиптә ресоциализациягә, социаль адаптациягә һәм социаль тернәкләндерүгә ярдәм күрсәтү турында гариза кергән затларның социаль хәлен карый һәм анализлый.

3.2. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ресоциализация, социаль адаптация һәм социаль реабилитация индивидуаль программасы нигезләмәләрен куллануны тикшерә һәм анализлый.

3.3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, аларны вәкаләтле органнарга, вәкаләтле вазифаи затларга җибәрә.

3.4. Муниципаль комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

3.4.1. Үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары, башка оешмалар һәм граждан җәмгыяте институтлары тарафыннан башкаруга тәкъдим ителгән карарларны кабул итәргә;

3.4.2. Үз артыннан җинаять яки административ җаваплылыкка тартылган законнарны бозу билгеләре ачыкланган очракта, гаепле затларны җаваплылыкка тарту мәсьәләсен хәл итү өчен тиешле документларны һәм материалларны хокук саклау органнарына җибәрергә.

3.5. Муниципаль комиссия пробация өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен үз компетенциясе чикләрендә пробация субъектлары булган органнар, учреждениеләр һәм оешмалар белән хезмәттәшлек итә:

3.5.1. Россия Федерациясе җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (аның территориаль бүлекчәләре) тарафыннан түбәндәге мәсьәләләр буенча:

хөкем ителгәннәрне, җинаять-хокукый характердагы башка чаралар билгеләнгән затларны һәм мәҗбүри эшләр рәвешендәге яисә авыр тормыш хәлендә калган затларны, пробация кулланыла торган затларның бердәм реестры операторы буларак җәзаларны үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән затларны исәпкә алу;

башкарма яки постпенитенциар пробация кулланыла торган затлар белән социаль һәм тәрбияви эш үткәрү;

ресоциальләштерүгә, социаль адаптацияләүгә һәм социаль тернәкләндерүгә индивидуаль мохтаҗлыкны бәяләүне уздыру;

башкарма яки постпенитенциар пробация куллану турында карарлар кабул ителгән затлар өчен индивидуаль программалар әзерләү;

коммерциячел булмаган, шул исәптән дини оешмалар, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан пробация үзәге эшчәнлеген оештыру.

3.5.2. Эчке эшләр органнары тарафыннан түбәндәге мәсьәләләр буенча:

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу;

башкарма һәм пенциар пробация куллану;

индивидуаль профилактик эш үткәрү;

хокукый белемнәрне пропагандалауда катнашу;

Россия Федерациясе гражданы паспорты белән хөкем ителүчене документлаштыру.

3.5.3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм аңа буйсынучы учреждениеләр (социаль яклау бүлекләре, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары) тарафыннан түбәндәге мәсьәләләр буенча:

халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау (хезмәт күрсәтү) өлкәсендә, шул исәптән мәҗбүри эшләр яисә ирегеннән мәхрүм итү рәвешендәге җәзаны үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм авыр тормыш хәлендә калган затларга социаль хезмәтләр күрсәтү һәм эшкә урнашуга ярдәм итү өлешендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

мәҗбүри эшләр рәвешендә яисә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче һәм авыр тормыш хәлендә калган учреждениеләрдән азат ителгән затларга карата социаль хезмәтләр күрсәтү өлешендә статистик мәгълүматны исәпкә алу;

социаль адаптацияләү үзәкләрендә, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар арасыннан социаль хезмәтләр алучылары белән билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен профилактик эш үткәрү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче балигъ булмаганнарны, шулай ук ирегеннән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән балигъ булмаган гражданнарны социаль адаптацияләү;

булган буш эш урыннары һәм вакантлы вазифалар турында, хезмәт шартлары турында, хезмәт хакы турында һәм вакансияләр эзләүчеләргә карата квалификация таләпләре турында мәгълүмат бирү юлы белән пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерүгә, социаль адаптацияләүгә һәм социаль реабилитацияләүгә ярдәм итү;

эшчәнлек өлкәсен (һөнәрне) сайлау, һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү максатларында билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган күрсәтелгән категориядәге затларга иректән мәхрүм итү урыннарыннан, һөнәри юнәлеш буенча бушлай дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү, социаль адаптацияләү буенча бушлай дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән эш бирүчеләрне, эшкә урнаштыручы затларны стимуллаштыру.

3.5.4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан беренчел медицина-санитария ярдәмен, профилактик һәм диспансер күзәтүен оештыру мәсьәләләре буенча;

3.5.5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гомуми белем, урта һөнәри белем алу, һөнәри белем алу мәсьәләләре буенча;

3.5.6. Шәхси счет ачу һәм индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган һәм индивидуаль счет иминият номеры турында белешмәләр булган документны рәсмиләштерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы социаль фонды бүлекләре тарафыннан пенсия тәэминаты алуда (аны алырга хокукы булган затлар өчен);

3.5.7. Дәүләт хакимиятенең башка органнары, җирле үзидарә органнары, граждан җәмгыяте оешмалары, институтлары тарафыннан аларның компетенцияләре нигезендә.

## 4. Муниципаль комиссияне төзү тәртибе

4.1. Муниципаль комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

Муниципаль комиссия рәисе:

муниципаль комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

хәлиткеч тавыш хокукына ия муниципаль комиссия утырышларын алып бара;

муниципаль комиссия утырышының көн тәртибен раслый;

муниципаль комиссия әгъзаларына үз вәкаләтләре кысаларында йөкләмәләр бирә;

муниципаль комиссия кабул итә торган документларны имзалый;

муниципаль комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

Муниципаль комиссия рәисе урынбасары:

комиссия рәисе кушуы буенча муниципаль комиссия рәисе вазифаларын ул булмаганда башкара;

муниципаль комиссия карарларының үтәлешен тикшереп тора;

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру чараларын планлаштыру һәм гамәлгә ашыру эшчәнлеген оештыра.

Муниципаль комиссия секретаре:

муниципаль комиссия рәисе йөкләмәләрен үти;

муниципаль комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра, аның утырышына кирәкле материалларны, тиешле карарлар проектларын әзерләү эшен координацияли, комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

муниципаль комиссия әгъзаларына һәм аның утырышына чакырылган затларга муниципаль комиссия утырышын уздыру урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җәза үтәү системасы учреждениеләре администрацияләреннән алына торган мәгълүматны, затны алда торган азат итү турында, аның торагы, эшкә сәләте һәм булган белгечлекләре барлыгы турында җыя һәм гомумиләштерә;

әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән затлардан, ресоциальләштерүдә, социаль адаптациядә һәм социаль тернәкләндерүдә ярдәм күрсәтү турындагы гаризаларны кабул итә;

озатып йөрү картасын һәм шәхси эшне ресоциализация, социаль адаптация һәм социаль тернәкләндерү программасының һәр катнашучысына һәм индивидуаль программа чараларын башкару буенча документлар һәм белешмәләр кертелгән шәхси эшне рәсмиләштерә;

«Пробация кулланыла торган затларның Бердәм реестры» дәүләт мәгълүмат системасының муниципаль сегментын алып бара;

муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазифаи затлардан муниципаль комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле документларны, материалларны һәм мәгълүматны соратып ала;

ведомствоара комиссия утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә;

утырышлар нәтиҗәләре буенча муниципаль комиссия рәисе йөкләмәләрен үтәүне оештыра;

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы халкына муниципаль комиссиянең функцияләре, аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирүне оештыра.

4.2. Муниципаль комиссия составы Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башлыгы карары нигезендә раслана.

4.3. Муниципаль комиссия составына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау оешмалары, мәгариф оешмалары вәкилләре керергә мөмкин (килешү буенча).

4.4. Муниципаль комиссия составына элек иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, ресоциальләштерү, социаль адаптация һәм социаль тернәкләндерү буенча уңай тәҗрибәгә ия затлар кертелергә мөмкин.

4.5. Муниципаль комиссия утырышларында Алабуга шәһәр прокуратурасы вәкиле катнашырга хокуклы (килешү буенча).

4.6. Муниципаль комиссия утырышларына муниципаль комиссия составына керми торган дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук башка оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

4.7. Муниципаль комиссия эшендә катнашу иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Муниципаль комиссия эше даими нигездә гамәлгә ашырыла.

5.2. Муниципаль комиссия утырышлары irектән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан, ресоциальләштерүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль тернәкләндерүдә ярдәм күрсәтү турында гаризалардан кергән саен, кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

Кирәк булган очракта муниципаль комиссия рәисе, аның урынбасары, шулай ук муниципаль комиссия әгъзасы инициативасы белән (муниципаль комиссия рәисе белән килештереп һәм секретарен тәкъдим итү буенча) муниципаль комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

5.3. Муниципаль комиссия утырышларын муниципаль комиссия рәисе, ә ул булмаганда яисә аның йөкләмәсе буенча муниципаль комиссия рәисе урынбасары алып бара.

5.4. Муниципаль комиссия утырышы составының яртысыннан күбрәге анда катнашу шарты белән хокуклы була.

5.5. Муниципаль комиссия карарлары киңәш характерында була һәм утырышта катнашучыларга ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала.

5.6. Муниципаль комиссия әгъзалары утырышларда карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия булалар.

5.7. Иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән зат теләге буенча утырыш әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән затларны чакырмыйча үткәрелә.

5.8. Муниципаль комиссия әгъзалары комиссия утырышында каралган мәсьәләләр турындагы белешмәләрне күрсәтелгән мәсьәләләргә кагылышлы затларның ризалыгыннан башка таратырга хокукы юк.

Гражданнарның хосусый тормышы турындагы белешмәләрне тараткан өчен муниципаль комиссия әгъзалары законнар нигезендә җавап тоталар.

5.9. Муниципаль комиссия эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатларында муниципаль комиссия рәисе рөхсәте белән, шәхси мәгълүматларны күрсәтмичә, массакүләм мәгълүмат чараларына тиешле мәгълүмат бирү рөхсәт ителә.